**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.05.2017 Балык Бистәсе штп. № 103пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 2014 елның 7 мартындагы 34пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 10 декабрь, 1072 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында " 2017 ел, 16 март, 145 нче карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 7 мартындагы 34пи номерлы «Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 08.08.2014 ел, № 147пи, 01.02.2017 ел, №15пи карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре, муниципаль китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

2.4 пунктта:

тугызынчы абзацта "урта буын белгечләрен « – 1,050" сүзләрен «квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр)– 1,347 " сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта:

«урта һөнәри һәм тулы булмаган югары белем,-1,166 " сүзләрен "урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем-1,570" сүзләренә алмаштырырга ;

унберенче абзацларда:

"профессиональ» сүзен төшереп калдырырга;

«1,284» санын «1,647»санына алмаштырырга;

унөченче абзацларда:

"профессиональ» сүзен төшереп калдырырга;

«1,224» санын «1,570»санына алмаштырырга

2.5 пунктының 2 таблицасында:

1 нче юлда «(тулы)» сүзен төшереп калдырырга;

2 нче юлда " Башлангыч һөнәри белем, урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем" сүзләрен "квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем" сүзләренә алмаштырырга ;

3 нче юлда «Югары һөнәри белем, аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр» сүзләрен «Югары белем – бакалавриат» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче юлда «Йомгаклау аттестациясен уңышлы узган затка «магистр» яки «дипломлы белгеч» сүзләрен «югары белем - специалитет яки магистратура»сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

сүз» "

"(тулы) " сүзен төшереп калдырырга;

"югары яки урта һөнәри белем» сүзләрен тиешле падежларда «югары белем - бакалавриат яки белгеч яки магистратура» сүзләренә алмаштырырга, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем» сүзләрен тиешле падежларда алмаштырырга.;

7 бүлек түбәндәге эчтәлекле 7.7, 7.8 пунктлары белән тулыландырырга:

«7.7. Авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 0,24 база оклады күләмендә билгеләнә.

7.8. Зарарлы, куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган авыр эшләр исемлеге, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы Россия комиссиясе фикерен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

2.7пунктын 2.6 пункты дип санарга;

4.6 пунктында «эш урыннарын аттестацияләү» сүзләрен «хезмәт шартларын махсус бәяләү»сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомуми тармак

һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

4.6 пунктында «эш урыннарын аттестацияләү» сүзләрен «хезмәт шартларын махсус бәяләү»сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

2.4 пунктта:

унынчы абзацта " урта һөнәри һәм тулы булмаган югары белем" сүзләрен "урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем" сүзләренә алмаштырырга;

унберенче һәм унөченче абзацларда "профессиональ" сүзен төшереп калдырырга;

2.5 пунктының 2 таблицасында:

1 нче юлда «(тулы)» сүзен төшереп калдырырга;

2 нче юлда " Башлангыч һөнәри белем, урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем" сүзләрен "квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем" сүзләренә алмаштырырга;

3 нче юлда «Югары һөнәри белем, аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр» квалификациясе" сүзләрен «югары белем – бакалавриат»сүзләренә алмаштырырга;

4 нче юлда «Йомгаклау аттестациясен уңышлы узган затка «магистр» яки «дипломлы белгеч» сүзләрен «югары белем - специалитет яки магистратура»сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

"(тулы) " сүзен төшереп калдырырга;

«югары яки урта һөнәри белем " сүзләрен тиешле падежларда «югары белем - бакалавриат яки белгеч яки магистратура» сүзләренә алмаштырырга, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем» сүзләренә алмаштырырга;

6.7 пунктында «эш урыннарын аттестацияләү» сүзләрен «хезмәт шартларын махсус бәяләү»сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2017 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. . Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин